| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.02.2017 № 104

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 21 мартында теркәлде, № 3856

Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 19.11.2014 ел, № 634 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидияләр-ташламалар бирүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидияләр-ташламалар бирү турында” 24.03.2006 ел, № 126 карары белән расланган тәртибе һәм шартлары хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә **боерык бирәм**:

Кушымта итеп бирелүче, Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан

Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 19.11.2014 ел, № 634 боерыгы белән расланган административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 27.02.2017 ел, № 104 боерыгы белән расландылар

**Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 19.11.2014 ел, № 634 боерыгы белән расланган административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1. 2.5 пунктның “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункты белән тулыландырырга:

“1.1. Күпфатирлы йортлардагы торак бүлмәләрнең милек хуҗалары, өстәмә рәвештә, аңа хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торакка хокукны билгеләүче документларның күчермәләрен тапшыралар.”.

2. 2.6 пунктның “Стандартка таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар кергән документлар алына:

иминиятләштерелгән затның барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләре күләме турында (ялгыз пенсионерларга, хезмәт ветераннарына, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга, авыл җирлегендә эшләгән һәм шунда яшәүче белгечләр исәбендәге пенсионерларга субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

эш бирүченең (иминиятләштертүченең) физик зат файдасына исәпләп язган

түләүләре һәм башка төрле акчалата бүләкләве суммасы турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

федераль законнарга туры китереп, ай саен бирелә торган акчалата түләүне алудан баш тарту турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең туктатылуы турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия ЭЭМнан);

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, әгәр иминият очрагы барлыкка килү нәтиҗәсе аларның һөнәри яктан хезмәткә яраклылыгын югалтуы булса, эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри чирләрдән иминиятләштерелгән гражданнарга яисә, әгәр иминият очрагы барлыкка килү нәтиҗәсе иминиятләштерелгән затның үлеме булса, – түләүләрне алу хокукына ия затларга түләнүче мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен бирелә торган иминият түләүләре турында мәгълүматлар (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондыннан);

эшсезләргә эшсезлек буенча пособиеләрнең һәм башка түләүләрнең барлык төрләрен түләү (түләүләрнең булмавы) турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен) (мәшгульлек үзәкләреннән);

тууны дәүләт теркәве турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (ЗАГС органнарыннан);

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (җирле үзидарә органнарыннан);

никахны дәүләт теркәве турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (ЗАГС органнарыннан);

никахны өзүне дәүләт теркәве турында (инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (ЗАГС органнарыннан);

инвалидка (инвалид балага) ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-

ташлама билгеләү өчен) (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

даими яшәү урыны буенча дәүләт хезмәте алучы белән бергә теркәлгән гражданнар турында (йорт кенәгәсеннән өземтә) (вәкаләтле органнардан);

аңа хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торакка милек хокукы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтеннән (алга таба – Росреестр));

опека (химая) билгеләнү турында (дәүләт хезмәте алучы 14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган зат булган очракта, законлы вәкилнең вәкаләтләрен раслау өчен) (җирле үзидарә органнарыннан).

Гариза бирүче Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына:

гариза бирүченең паспортының чынлыгы турында мәгълүматлар (Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгыннан).

Гариза бирүче бу пунктта күрсәтелгән мәгълүматлардан торган документлар тапшырырга хокуклы, шул исәптән, мөмкинлек булганда – электрон рәвештә.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтеп үтелгән мәгълүматларны эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тартуга нигез булып тормый.

Гариза бирүче тапшыруга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе бу Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап кителгән документларны гариза бирүчедән таләп итү тыела.”.

3. 3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3.4.2. Үзәк бүлегендә субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булмаганда, Үзәк бүлеге белгече, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, түбәндәге мәгълүматларны бирүне сорап, электрон рәвештә рәсми мөрәҗәгатьләр

җибәрә:

иминиятләштерелгән затның барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан социаль түләүләре күләме турында Россия Федерациясе Пенсия фондына;

эш бирүченең (иминиятләштертүченең) физик зат файдасына исәпләп язган түләүләре һәм башка төрле акчалата бүләкләве суммасы турында Россия Федерациясе Пенсия фондына;

пенсия алу, билгеләнү, алмау турында һәм түләүләрнең туктатылуы турында Россия ЭЭМга;

медицина-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча, әгәр иминият очрагы барлыкка килү нәтиҗәсе аларның һөнәри яктан хезмәткә яраклылыгын югалтуы булса, эштәге бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри чирләрдән иминиятләштерелгән гражданнарга яисә, әгәр иминият очрагы барлыкка килү нәтиҗәсе иминиятләштерелгән затның үлеме булса, – түләүләрне алу хокукына ия затларга түләнүче мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен бирелә торган иминият түләүләре турында Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондына;

2013 елның 23 октябренә кадәр туган балаларны дәүләт теркәве турында ЗАГС органнарына;

никахны дәүләт теркәве турында ЗАГС органнарына;

никахны өзүне дәүләт теркәве турында ЗАГС органнарына;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында җирле үзидарә органнарына;

ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында җирле үзидарә органнарына;

опека (химая) билгеләнү турында җирле үзидарә органнарына;

даими яшәү урыны буенча дәүләт хезмәте алучы белән бергә теркәлгән гражданнар турында (йорт кенәгәсеннән өземтә) вәкаләтле органнарга;

аңа хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торакка милек хокукы турында Росреестрга;

әгәр гариза Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелсә, гариза бирүченең паспортының чынлыгын раслау турында Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына.

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктлар билгели торган процедуралар гариза һәм документлар кабул ителгән һәм теркәлгән көнне үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган һәм “Татарстан Республикасы халкының социаль регистры” дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның “Социаль ярдәм чаралары” кече системасына кертелгән мәгълүматлар, мәгълүматлар бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.”.